Балык бистәсе районы Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе



# Яңа көн

Октябрь 2018 № 2

*Хөрмәтле укытучылар һәм укучылар! Менә инде уку елының икенче аена аяк бастык. Бу айда бәйрәмнәр бик күп. 1 октябрь - өлкәннәр көне, 5 октябрь - укытучылар көне. Без чын күңелдән укытучы абый-апаларыбызны шушы матур бәйрәм белән котлыйбыз. Сезгә ныклы сәламәтлек, бәхетле озын гомер, җан тынычлыгы телибез!*

## Бу санда

Өлкәннәр көне белән!

Яңалыклар

Укытучылар бәйрәме котлы булсын!

Хөрмәтле укытучыларыбыз! Сезне чын күңелдән һөнәри бәйрәмегез – Укытучы көне белән котлыйбыз! Бүгенге истәлекле көндә барлык укытучыларга рәхмәт сүзләре белдерәсе һәм хөрмәт күрсәтәсе килә. Сезнең профессиональ, игътибарлы, таләпчән булуыгыз һәм күңел җылыгыз безнең сәләтләрне һәм талантларны ачарга ярдәм итә. Әлбәттә, укытучы хезмәте беркайчан да җиңел булмады, бүген ул тагын да катлаулырак. Укытучы эше зур түземлелек, даими камилләшү таләп итә. Укытучы – ул һөнәр генә түгел, укытучы булып туарга кирәк! Мәктәптә үткәргән һәр көнегез балалар белән аралашудан шатлык китерсен! Укучылар үз белемнәре белән куандырсын, ә мәктәпне тәмамлаучылар туган мәктәпләрен һәм яраткан укытучыларын онытмасын! Бу сезнең хезмәтегез өчен иң югары бәя!

# 1 октябрь -Өлкәннәр көне

Авыртмасын саның, сыкрамасын жаның,
Көләч йөзең һаман яктырсын.
Ходай сиңа картлык көннәреңдә
Рухи өмет, шатлык артырсын.
Теләкләрне кайсын теләсәк тә,
Аз булыр күк синең хөрмәткә.
Аяз булсын мәңге күңел күгең,
Без калабыз шушы теләктә.





**5 класс укучылары Шайхутдинова**

**Минниса апада шефлыкта**


7 класс укучылары

ветеран укытучы

Сәкинә апаны икеләтә

бәйрәме белән

котларга бардылар



# Кызыклы сорашу

Без күп кенә укытучылар турында кызыклы мәгълүмәт җыерга тырыштык. Һәм менә берничә укытучы белән булган кызыклы вакыйгалар һәм алар турында фактлар.



” Мин йөзергә бик яратам. Күптән түгел укытучылар спартакиадасында йөзү буенча ярышларда катнаштым. Машинада йөргәндә тизлек яратам. Үзем малаемны “Куып йөрмә”, дип гел әрлим, ә үземә Казанга барып кайткан саен сәлам хатлары килә.”



” Бик тәмле ашарга, йокларга яратам. Бакча тутырып чәчәк үстерәм. Кеше ишетмәгәндә рәхәтләнеп җырлап йөрим. Урман-кырларда гөмбә, җиләкләр җыям.”



“1 класста дәрес бара. " На ферме" дигән текст укыйбыз. Зөлфия шаярып утыра. “Карап бар”,- дип кисәту ясыйм.” Эй, Апа, карамасам да беләм инде мин ферма хәлләрен. Ужас анда. Әни янына йөз төшкән мин”

”Мин пешкән суган яратмыйм. Тәчкерә башласам, кимендә 5 тапкыр рәттән төчкерәм. Шпагатка утыра алам, мостик тошәм, кухняда яулыксыз һәм алъяпкычсыз йөрмим, тынычлык яратам, урманда йөрергә, җиләк җыярга, су коенырга яратам.”





Моннан берничә ел элек, 10нчы класста “тригонометрик функцияләр” темасын үткәндә, бер укучыны такта янына мисал чишәргә чыгардым. Бирелешне китаптан күчергәндә, sin π/6 дип язасы урынга sos π/6 дип язган, өстәвенә чишәдә алмый тора... Ярдәм итәргә туры килде инде.




” Тәмләп яңа парланган чәй эчәргә яратам, ятуга йокыга китәм, кечкенә балаларны бик яратам, ничек кенә арып кайтсам да,теплицада йөреп, кыяр-помидорларны, җиләкләрне рәтләргә яратам. Үземнең һәм гаиләмнең сәламәтлеген гел кайгыртып торам. Ялганны һәм гаделсезлекне, эшсезлекне яратмыйм”

” Наушник киеп, музыка тыңлап, биергә, кычкырып җырларга яратам. Хайваннар белән сөйләшәм.”





”Биеклектән бик нык куркам. Яңгырны яратам, шунлыктан кулчатыр күбрәк өйдә кала”



“21 саны минем өчен бәхетле сан: туган көнем, булачак тормыш иптәшемне очраттым, никах көнебез, туй көнебез, һ.б.

Мәктәптә укыганда врач булырга тели идем, ак халатлы врачларга хәзер дә кызыгып карыйм”

# Яңалыклар!!!

"Экстремизмга - юк!" декадасында мәктәбебездә ОБЖ укытучысы Набиуллин Н.А. житәкчелегендә эвакуация укулары уздырылды. Техник хезмәткәрләр, укытучылар, укучылар бирелгән вакытка сыешып, 1 мин. 49сек. эчендә тиешле урынга жыелып беттеләр.



Бакчаларда да күптәннән инде эшләр башланды, һәммә кеше дә, салкын көннәр башланганчы тырышып-тырмашып уңышларын җыялар. 15 сентябрь көнне безнең мәктәп бакчасында да өмә булып узды.



19 сентябрь көнне 11 класс укучылары рус теленнән ABBYY мониторингта катнаштылар.



"Укучының мәдәни көндәлеге" мәдәни - мәгарифле проект кысаларында башлангыч сыйныф укучылары белән Бердәм мәдәни дәрес уздырылды.

